**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урманай авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

Урманай авылы №05/91 07 апрель 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 июненнән 16/100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында (19.10.2018 № 30/114, 19.03.2019 №06/129, 19.08.2019 № 21/144 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Урманай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 июненнән 16/100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында (19.10.2018 № 30/114, 19.03.2019 №06/129, 19.08.2019 № 21/144 карарлар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Э.Р.Абдуллина